СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

17 сентябрь, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 104 (8116) | Бәясе билгеләнгәнчә

**Бүген «Норлатнефть» НГДУсы базасында кара алтын чыгаручыларның Бөтенроссия семинары була. Семинарда катнашучыларны сәламлап, нәтиҗәле эш, уңышлар телибез.**

*(Аңа кагылышлы материалны газетабызның 3 нче битеннән укыгыз).*

## ИГЕНЧЕНЕҢ МӘШӘКАТЕ КИМЕМИ

### Ашлык - дәүләткә

### «Таң» - беренче

**Район хуҗалыклары ашлыкны дәүләт амбарларына саклауга салу эшен элеккечә эзлеклелек белән дәвам итәләр. Кичәге көнгә элеваторга 83 мең тоннага якын, шул исәптән 50 мең тоннадан күбрәк ашамлык бодае керде.**

**«Таң» крестьян кооперативлары берлеге күтәренке заданиене тулаем да, шул исәптән ашамлык бодае буенча да беренче булып тутырды. Хуҗалыктан элеваторга 2300 тонна тирәсе ашлык керде, шуның 1235 тоннасы - бодай.**

**Тагын өч - «Төрнәс», «Рассвет» һәм «Игенче» хуҗалыклары бодай тапшыру буенча күтәренке заданиене уңышлы башкарып чыктылар.**

### «Урак-97» матбугат үзәге хәбәр итә

Районда урып-җыю эшләре азакка якынлаша. Оператив мәгълүматлардан күренгәнчә, 16 сентябрьгә барлыгы 45.107 гектардан, ягъни барлык мәйданнарның 92 процентыннан игеннәр урып җыелды. Шушы көнгә 29.941 гектарда туңга сөрү үткәрелде. Бу - планлаштырылганның 45 проценты кадәр. Бу эш соңгы бер көндә 1.327 гектарда башкарылды.

Кукуруз 4.538 гектардан (планның 61 проценты) урып-җыелды, 55.725 тонна (35 процент) силос хәзерләнде.

16 сентябрьгә район буенча орлык запасы 9.975 тонна (планның 97 проценты) тәшкил итә.

Район басуларында икенче урак башланды. «Кондырча», Кузнецов исемендәге, «Киекле», «Рассвет» ассоциацияләре чөгендер казытуга оешканлык белән керештеләр.

### Рәшит һаман беренче

«Алга» КХАннән **Рәшит Кәлимулла улы Насыйбуллин** район комбайнчылары арасында беренчелекне бирми. «ДОН-1500» комбайны бункерыннан 26.336 центнер ашлык бушатты ул.

МТСның җыелма отрядыннан «Кейс» комбайнчылары **Василий Ильич Таймуллин** һәм **Владимир Владимирович Булатов** 25.362, **Фәрит Сәлих улы Җәлалов** һәм **Фәнис Талип улы Гаязов** 23.359 центнер ашлык суктырдылар.

Мичурин исемендәге КХА комбайнчылары **Иван Валерьянович Николаев** «Нива» комбайны бункерыннан 14.600, Алексей Ильич Исаев 14.123 центнер ашлык бушаттылар.

### ЧАКЫРУ

**Хөрмәтле якташлар!**

**Сезне 1997 елның 20 сентябрендә Октябрь районының Киекле авылында икенче мәчет ачылу тантанасына чакырабыз.**

**Бәйрәм иртәнге сәгать 10 да башлана.**

**Мәчет мөтәвәллияте.**

## Район Советы семинар үткәрде

Җирле үзидарә Советлары практикасында кадрларны өйрәтү һәм үзара тәҗрибә уртаклашу юнәлешендә зур тәҗрибә тупланды. Авылда барлык сукмаклар да Советка илтә дип юкка гына әйтелми, шуңа күрә дә анда эшләүчеләр күп мәсьәләләрдә компетентлы, билгеле бер дәрәҗәдә хокук белемнәре потенциалына, кешеләр белән эшләү тәҗрибәсенә ия булырга тиешләр. Шуңа күрә дә җирле үзидарә Советлары җитәкчеләренең узган шимбәдә Киекле Советы территориясендә булып үткән семинар - киңәшмәсенең программасы максатларының күптөрлелеге һәм конкретлыгы белән аерылып тора иде. Җирле үзидарә Советы территориясе чигендә кунакларны ипи -тоз белән «Киекле» КХАсы һәм Совет рәисләре Н.Ш.Шарапов белән Ю.Х.Садыйков каршы алдылар. Шунысын да әйтергә кирәк, хуҗалык җитәкчесенең бу чараның башыннан ахырынача үзе дә катнашуы эшлекле очрашуның әһәмиятлелеген көйчәйтте генә.





Семинар - киңәшмәнең гамәли өлеше кунакларны җирле үзидарә Советы территориясендәге социаль -мәдәни объектлар, клублар, мәктәпләр, фельдшер - акушерлык пунктлары белән таныштырудан башланды. Берочтан монда газлаштыру эшләренең барышына һәм кышкы ягу сезонына әзерлек мәсьәләләренә зур игътибар бирелде. Хуҗалык һәм Совет җитәкчелегенең уртак тырышлыгы белән биредә Киекле авыл клубының асылда инде өч ел эшләмәгән җылыту системасын ремонтлау тәгәлләнеп килә. Клуб эчендәге эшне камилләштерү буенча да чаралар күрелә. Семинарда катнашучылар хуҗалыкның Киекле товарлыклы - сөтчелек фермасында булып биредә монтажланган швед сөт саву җайланмасын карадылар, терлекчелек фермалары тирәләрен төзекләндерү, анда һәм килү юлларына асфальт җәю буенча күп эш башкарган НУАД коллективының зур гамәли ярдәмен билгеләп үттеләр.

Семинар - киңәшмәнең Кизләү авыл мәдәният йортында дәвам иткән икенче өлешендә җирле үзидарә Советлары рәисләре алдында Киекле җирле үзидарә Советы хезмәткәрләре А.И.Шәмсетдинова һәм З.В.Әхмәтҗанова чыгыш ясап, халык белән эшләүне оештыру, Совет утырышларын әзерләү һәм үткәрү, эш кәгазьләрен алып бару, салымнар җыю, шәхси эшмәкәрлеккә контрольлек итү һәм башка мәсьәләләрдә тәҗрибә уртаклаштылар. Залдагылар аларга күп кенә сораулар да бирделәр.

Аннан соң җирле Совет җитәкчеләренең «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законын һәм Совет Уставын ничек белүләре имтихан билетлары буенча тикшерелде. Моңа шулай җитди игътибар бирелүе очраклы түгел, чөнки халык Совет башлыгының хокукый базаны ни дәрәҗәдә белүе һәм куллана алуыннан чыгып җирле власть органының нәрсәгә сәләтле булуы турында да фикер йөртә бит. Бу җәһәттән җавапларның һич тә начар булмавы игътибарга лаек иде.

Семинар - киңәшмә эшенә халык депутатлары район Советы рәисе урынбасары вазифаларын башкаручы А.Н. Ельченков йомгак ясады. Бу чара җирле Советларның алдагы көндәлек эшчәнлегендә шактый ук файдага булыр дип уйларга кирәк.

**Рәсемнәрдә: семинар-киңәшмәдән күренешләр.**

## БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШ

Узган җомгада район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногманова җитәкчелегендә «Дәүләт пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштергән) учет турындагы» Федераль Законны гамәлгә ашыру буенча район эшче төркеменең беренче, оештыру - таныштыру утырышы булды.

Утырышта әлеге Законны тормышка ашыру этаплары һәм бу эшнең кайбер махсус үзенчәлекләре турында җентекле итеп Пенсия фондының район буенча вәкиле В.Г.Хоменко сөйләде. Район төркеме әгъзалары арасында хезмәт коллективларында аңлату - оештыру эшләре үткәрү өчен вазифалар бүленде. Шундый чараларның иң мөһиме итеп урыннарда 1 октябрьгә кадәр эшче төркемнәр оештыру һәм приказ тәртибендә әлеге участоклар өчен җаваплы кешеләр билгеләү тора.

Бу хакта белешмәләрне сез газетабызның 3 нче битеннән укый аласыз.

**Бер генә көн калды!**

### Хөрмәтле дуслар!




**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу игълан ителде. Язылу бәясе ярты елга 26.4000, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

***8 сентябрьдән 18 сентябрьгә кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасына льготалы язылырга мөмкин. Аның бәясе - 19.800 сум.***

Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.

# ИҢ КАДЕРЛЕ КУНАК ИТЕП

Ул көннән соң Наилә ни үле, ни тере йөрде. Балаларга каникуллардан соң мәктәпкә барасы, ә Ваня белән Эдикның өсләренә кигезерлек бер күлмәк тә, костюм да калмаган. Хәер, үзенең дә кешегә киярлек киеме юк: барысы да янып бетте. Ярый ла, янгын бер бүлмәдән калганнарына үрли алмады. Югыйсә, балаларның тугызысы да, үзләре дә япа - ялангач каласылар иде. Кечеләре - нәни Равилнең ут белән шаяруы шундый зур бәла китерде гаиләгә. Ярый ла, янәшәдә яхшы кешеләр булды: Наилә эшли торган шифаханә администрациясе каза күрүче гаиләсенә тиз арада бер миллион сум акча бирде. Ялангач йөрмәсләр бит инде, балаларга, үзенә киемгә тотты аны хатын. Тулаем кара көйгән өч бүлмәле фатирны шул акчага төзәтү хәлләреннән килмәс иде, барыбер.

- Ятып калганчы атып кал, диләр, әллә район җитәкчесе янына барып карыйсыңмы.

Кайгы белән әлеге киңәшне бирүчене төгәл хәтерләми дә хәзер Наилә, әмма аңа бик рәхмәтле. Тотты да хәлен аңлатып Ф.С.Сибагатуллин исеменә хат язды Наилә. Берничә көннән аны хакимият башлыгы үз бүлмәсендә кабул итте.

- Йортны бүләк итеп салып бирәбез сезгә...

Фатих Сәүбәновичның шушы сүзләрен ишеткәч, ни еларга, ни көлергә белмәде хатын. Янып китүчеләр дә, безнең кебек зур гаиләлеләр азмыни районда, булмас бу,- дигән шик яши иде аның күңелендә. Шул ук вакытта йөрәгендә өмет чаткысы да яшәде: район хәтле район җитәкчесе йортның кайда төзеләсен үк әйткән икән, димәк, сүзләр бушка булмас. Ә инде июнь башларында йортка фундамент салынгач үзенең дә, ире Евгенийның да, балаларның да сөенечләре эчләренә сыймады.

Йорт күзгә күренеп өскә үрләде. Июль урталарында МСОның 1 нче ПМКсы йортны тулысынча «аякка» бастырды. Хәбир Вәлиевның балта осталары, Ринат Хөснуллинның монтажчылар, Зинаида Шәрәфетдинованың буяучылар бригадасы барысы берьюлы эшләделәр бу объектта. Һәрвакыттагыча, материал, эшче көч җитешмәү сәбәпле чатаклыклар да булмыйча тормады. Әмма район хакимияте башлыгының аерым контроле астында төзелә торган бу объекттагы эшләрнең барышын МСО җитәкчеләре дә һәрдаим игътибар үзәгендә тоттылар.

- Сөенечебез эчебезгә сыймый. Фатих Сәүбәновичка рәхмәтнең ниндиен әйтсәк тә, аз булыр сыман,- диләр Белоусовлар.


Сөенмәслек тә түгел. Элеккеге фатирлары өч бүлмәле булса да унбер җан өчен бик кечкенә иде шул. Шәһәр Советында торак шартларын яхшырту буенча ун еллап чиратта торсалар да зуррак фатирлы булу турында хыялланалар гына иде. Ә менә хәзер... СПТУ микрорайонында төзелгән, мансардалы бу йортның бүлмәләре генә дә бишәү, зурлар, яктылар - җәмгысе 140 квадратлап җыела. Кухня, санузел да уңайлы. Паркет идәннәр, фигуралы рейкалардан ясалган түшәм, төрледән - төрле бизәкле обойлар, ачык тондагы буяулы зур веранда - барысы да искиткеч. Хәтта йорттан капкагача тротуар да салынган. Йорт тирәсе тотып алынган: киләсе елдан Белоусовлар яшелчәне үз йортлары янында үстерәчәкләр, димәк.

- Күктән иңгән зур бәхет бу безнең өчен. Башка кайгы күрмичә балаларым, гаиләм белән тыныч яшәп, өйнең рәхәтен күрергә язсын ходай,- ди йорт башлыгы Евгений Иванович та шатланып. - Мондый йортны без үз көчебез белән мәңге җиткезә алмый идек әле.

... Белоусовлар якын көннәрдә әлеге йортта яши башлаячаклар. Өй туен үткәрүне дә озакка сузмаска ниятлиләр. Чакырыласы кунаклар исемлегендә иң беренче булып Ф.С.Сибагатуллин фамилиясе тора.

- Кайгыбызны күтәрешкәч, шатлыгыбызны да уртаклашыр, шәт. Зурлап, олылап барып чакырырга ниятлибез үзен,- диләр Белоусовлар.

**Р.ГИНЯЕВА.**



**Рәсемдә: Белоусовларның яңа йортлары менә шундый. Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Алар исемнәрен урамнарыбыз йөртә

## Габдулла Тукай исемендәге урам



Татар халкының бөек шагыйре Габулла Тукай (1886 - 1913 еллар) Татарстан Республикасы хәзерге Арча районының Кушлавыч авылында туа.

4 яшеннән тома ятим калып, ул тормышның ачысын - төчесен күп татый. Уральскига күчеп, мәдрәсәдә белем ала, рус классында укый.

Шигырьләрне ул 1902 елдан яза башлый. Типографиядә хәреф җыючы булып эшли, «Фикер» газетасына, «Әл - гасрел - әл - җәдит» журналына язып тора, анда шигырьләрен, публицистик әсәрләрен, фельетоннарын бастыра.

1907 елда Казанга күчеп килә, анда язучы - демократлар белән аралаша башлый. Г.Камал белән берлектә «Яшен» сатирик журналы чыгара башлый, «Ялт - йолт» журналында эшли. Шигырьләрендә һәм памфлетларында монархистлар һәм буржуаз милләтчеләрне фаш итә. Тукай иҗатында иң төп тема булып революцион заманчалык, халык массаларының ирек өчен көрәше мәсьәләләре тора. Шагыйрьнең туган якка, халык авыз иҗатына мәхәббәте нәтиҗәсендә «Шүрәле» поэмасы туа.

Тукай - татар реалистик тәнкыйтенә нигез салучы. Татар халкының бөек җырчысы, татар әдәбиятында демократик һәм революцион юнәлешләргә нигез салучы иң беренче итеп халыкка хезмәт итү, аның ирекe өчен көрәшүне алга куя.

Тукай - милли әдәби - шигъри телне тудыручы. Нык инанган шагыйрь - интернационалист, ул Пушкин, Лермонтов, Майков шигырьләрен татарчага тәрҗемә итә.

Тукай шигырьләре дөнья халыкларының күп телләренә тәрҗемә ителде. Тукай иҗаты - әдәбияты ягыннан XX гасыр дөнья, гомумкешелек мәдәниятында олы өлеш алып тора. Татар халкының бөек улының 100 еллыгы ЮНЕСКО карары буенча дөньякүләм масштабтагы вакыйга буларак билгеләп үтелде.

## СПИРТЛЫ ЭЧЕМЛЕКЛӘРГӘ ТАГЫН БЕР «ЙОЗАК» КУЕЛА

1 сентябрьдән Русиядә һәм шул исәптән Татарстанда да алкоголь эчемлекләр сатуда чираттагы чикләү кертелде. Хәзер спиртлы эчемлекләр шешәләрендә металлдан эшләнгән маркалар булырга тиеш. Аларны бары тик Госзнак фабрикасында гына эшлиләр.

Татарстанда эшләнгән алкоголь эчемлекләргә (әгәр дә алар Республикада гына сатылса) бу чикләү 30 сентябрьдән соң керәчәк. Русиянең башка регионнарына чыгарганда һәм Татарстанга читтән кергән спиртлы эчемлекләр өчен металл маркалар 1 сентябрьдән үк булырга тиеш.

## Проблема ничек хәл ителә?

# ӨЙЛӘР ҖЫЛЫ КӨТӘ

Укучы хәтерлидер булса кирәк, быелгы кышның уртасында әле җәй җылысы килергә 3 - 4 ай вакыт калганда шикәрчеләр поселогындагы 5 - 6 урамга сузылган җылылык торбалары эштән чыгып бушап калган иде. Ә менә шул йортларда яшәүчеләр бу көннәрне тиз генә оныта алмаслар әле. Ул чакта кем ничек булдыра ала шулай җылынды, бөтенләй кыш суыгында яшәүчеләр дә булды.

Бүген көннәр көзгә авышканда бу өйләр кышка ничек керергә җыена соң? Аларга җылылык кертеләме?

Хәлнең торышын ачыклау максатында безгә август ае башында шәһәр җирле үзидарә Советы рәисе Р.Г.Билалов белән бәйләнешкә кереп, шикәрчеләр поселогында яшәүчеләр янында булырга туры килде. Равил Габдрахманович әйтүенчә, бу хәлиткеч мәсьәлә игътибар үзәгеннән төшми. Нәкъ шул чакта поселоктагы 140 шәхси йортка җылылык кертүгә план төзелгән дә иде. Шәһәр мэриясе район хакимияте белән берлектә әлеге йортларны яңадан котельняга тоташтыруга караганда поселокка табигый газ кертүнең күпкә отышлырак буласын исәпли һәм алга куелган ниятне гамәлгә ашырырга керешә. Иң мөһиме, бу җаваплы эшкә алынып тиз һәм кыска вакытта очына чыгарлык җитди подрядчы табу мәсьәләсе алга килеп баса һәм бу эш «Норлатгаз» производство - эксплуатация идарәсенә йөкләнә. Күптән түгел шикәрчеләр поселогына икенче тапкыр нәкъ шул идарәнең баш инженеры Н.И.Мокриков белән барырга туры килде. Әйтергә кирәк, 1 ай эчендә әлеге 140 йортны газлаштыру буенча гаҗәеп күп эш башкарылган. Газ кертү буенча тәҗрибәле белгеч буларак, Николай Иванович та нәкъ шул фикерне куәтли: «шундый эш темпын күрергә туры килгәне юк иде әле», ди, «Востокмонтаж» АҖнең Отрадныйдагы 2 нче төзелеш участогыннан 10 һәм Әлмәт шәһәре СКБУ төзелеш участогыннан 7 кеше тарафыннан Циолковский урамының бер өлешенә, Маяковский, Тукай урамнарына, алар арасындагы тыкрыкка 360 тәрәк куела, 3 км. чамасы участокта төрле диаметрдагы торбалар монтажлана. Бүгенге көндә юл аша чыгара торган компенсаторлар гына ябыштырылмый кала һәм заказчының (МПП) торбаларны буявы көтелә. Хәер, Николай Иванович фикеренчә, ул көн саен әлеге участокта подрядчылар башкарган эш сыйфатын тикшереп тора. Заказчы эшен үзвакытында башкарса, бу бер атналык эш һәм бу җәһәттән тоткарлык булмаска тиеш. Алга таба да көтелмәгән кыенлыклар, түләү мәсьәләсендә проблемалар килеп чыкмаса, октябрь урталарына сыек ягулык өйләргә керә башлаячак ди ул.

Ә өйләргә килгәндә йорт хуҗалары газ кертүгә әзерме соң? Әлеге 140 йортның байтагында олы яшьтәге кешеләр яши. Шуларның берсе Маяковский урамында яшәүче С.Хасямовага кердек.

- Өметләнмибез дә инде,- дип каршы алды ул безне. Шуңа карамастан газ миче алынган, аерым бүлмәгә урнаштырылган, газ кертүгә документациясе әзерләнеп 1 млн. акчасы да түләнгән. Аның әйтүенчә, һәр йортта шундый әзерлек бар. Ләкин акча мәсьәләсендә чатаклыклардан котылып калып булмас әле, чөнки хуҗалар акчаны бүген аларга газ кертү белән шөгыльләнүчеләргә түгел, ә алдан эшләргә тиеш булган башка төзелеш участогына түләгәннәр булып чыкты. Бу факт газ кертүнең һаман да гаять катлаулы һәм четрекле мәсьәлә икәнлеген дәлилли дә.

Кышын җылылык өзелгән башка урамнарга килгәндә, аларда да газ кертү эшләре бара. Тик аларның заказчылары да, подрядчылары һәм эш темплары да башка.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# «НОРЛАТНЕФТЬ» ТӘҖРИБӘСЕ - БӨТЕН РОССИЯ ӨЧЕН

## (Бүген «Норлатнефть» НГДУсы базасында Бөтенроссия семинар - киңәшмәсе үтә)

***Семинар - киңәшмәнең төп темасы «Нефть чыгаруда автоматлаштырылган системалалар һәм аз кеше эшли торган технологияләр кертү». Нефть компанияләре, фәнни - тикшеренү һәм проект институтлары вәкилләре, технология эшләүчеләр һәм башкаручылар, барлыгы 200 ләп кеше, болардан тыш «Татнефть» берләшмәсе төп белгечләре, Татарстан Республикасында нефть һәм газ чыгару идарәләре начальниклары, баш инженерлары һәм баш энергетиклары катнашачак бу зур чара Кутуш нефть ятмасы базасында үтәчәк.***

### НОРЛАТ ПИОНЕРЛАРЫ

«Норлатнефть» НГДУсы станок - качалкаларны автоматлаштырып идарә итү кебек катлаулы технологияне үзләштерүдә «Татнефть» күләмендә генә түгел, аның ерак чикләрендәге тәрдәш предприятиеләр арасында пионер булып тора. Бүген Норлат нефть чыгаручылары 15 станокны «читтән» торып идарә итәләр. Якын арада аларның саны 60 ка җитәчәгенә өмет итеп була: проектлары әзер. Ә бу эштә проект зур нәрсә. Кутушта да бу зур эш нәкъ менә проекттан башланган иде. Бөгелмәдәге «Татнипинефть» проект институтында эшләтеп алып, Чабаксардагы Бөтенроссия фәнни - тикшеренү институтыннан җиһазлар кайтардылар. Ә тулаем алганда бу катлаулы процессны гамәлгә кертүдә идарәнең байтак хезмәтләре тир түкте. Геологлар нефть ятмасының үзенчәлекләрен өйрәнделәр, беренчел датчиклар - монометр, счетчикларны промысел кайгыртты, автоматлаштыру цехы өлешенә дә эшнең күләмлесе төште. Төп эш исә энергетикларның аерым контроле астында барды.

### СТАНОК -КАЧАЛКАНЫ ЭВМ ИДАРӘ ИТӘ

Элек станокның эшенә операторлар күзәтчелек итте. Һәрбер качалка янында булып, ә «Норлатнефть» НГДУнда алар җәмгысе 800 ләп җыела, барлык параметрларны контрольгә алырга кирәк иде. Станоклары таркау булган Кутуш нефть ятмасында барлык нефть суырту җиһазларын карап - күзәтеп бетерү ай - һай авыр булды. Дистәләгән оператор көне - төне станоктан - станокка сукмак таптыйлар иде. Билгеле инде, моның чыгымнары да аз булмады. Ә хәзер... Станок кеше катнашыннан башка, пульт ярдәмендә идарә ителә. Ә төп асылы түбәндәгедән гыйбарәт. 10 киловольтлы линия буенча станоктан информация 3 нче нефть һәм газ чыгару цехы (ЦДНГ, Кутуш әлеге цехка карый) диспетчерлык пунктына һәм ПРЦЭ и Э га килә. Моның өчен өстәмә кабель линияләре тарту таләп ителми, аңлашыла ки, монтаж эшләре арзаная. Гомумән, бу технологиянең өстенлекләре бик зур. Алда әйткәнебезчә, станок - качалка һәм подстанция белән диспетчерның персональ ЭВМ нан идарә итү мөмкин. Станокның эше, чыгу өлешендәге басым, куәт, су чыгымы турында - барлыгы 40 лап параметр буенча мәгълүмат алып була. Станокны туктату, эшкә җибәрү мөмкинлегенә дә ия ЭВМ. Станокта чатаклык килеп чыкканда да диспетчер шунда ук бу турыда информация ала. Бүгенге төсле металлга кул сузучылар күбәйгән заманда ЭВМ ның угрылар кулына сугу мөмкинлеге бар.

Гомумән, яңа технологиянең өстенлекләре зур. Диспетчер, мәсәлән, станокның тирбәлү санын исәпкә алып, аның нефть чыгару мөмкинлеген төгәл санап чыгара яисә җитештерүчәнлеген максимальгә кадәр арттыра ала.

Кыскасы, ЭВМ күп нәрсә булдыра.Бүгенге экологик кризис чорында, кеше катнашыннан башка ул чыбыклар аркылы газ чыгуны үлчи ала.

* * *

Билгеле инде, нефть чыгаруга автоматлаштырылган системаларны кертү җиңел процесс түгел. Әмма идарәнең баш энергетигы Р.Р.Мәхмүтов әйтүенчә, әлеге технология якын арада үзен үзе аклаячак. Россия күләмендәге семинарның безнең идарә базасында үтүе үзе үк шул турыда сөйли. Димәк, Норлат нефтьчеләре тәҗрибәсе бөтен Россиягә таралачак.

**Р.ГИНЯЕВА.**



Рәһәбәр апаның шулай башына чигүле ап - ак яулык бәйләп, өстенә матур кофталар киеп, кул кушырып, ял итеп утырганын сирәк күрәсең. Гадәттә ул яулыгын арттан бәйләп, өстенә җиңелчә халат киеп, җил - җил эшләп йөрергә күнеккән. Югыйсә, балалары да үсеп таралып беттеләр, үзе дә сыер савучы булып эшләп, пенсия яшенә җитте. Әмма Рәһәбәр үзе генә үзгәрми: һаман да шул балалар дип борчыла, һаман да шул ферма юлыннан аралана алмый. Җитезлеге, өлгерлеге дә кимеми. Элек фермада ничек эшләгән булса, хәзер дә шулай. Быелның сигез аенда һәр сыердан уртача өч мең килограммнан артык сөт савып алуы да шул хакта сөйли.

**Рәсемдә: «Дуслык» КХАсы сыер савучысы Р.ҖИРҖИЗОВА.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Дәүләт пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) учет турында

1997 елның 1 гыйнвареннан «Дәүләт пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) учет турында» Федераль Закон үз көченә керде. Шул законның нигезләмәләрен тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1997 елның 17 июнендә 494 нче карар кабул итте, шуннан чыгып район хакимияте башлыгы да 12 августта 333 нче карарын чыгарды.

Нинди Закон соң ул һәм нәрсәне күздә тота? Федераль Закон нигезендә Пенсия фондында һәр эшләүчегә аның исәбенә предприятие тарафыннан күчерелгән пенсия иминияте кертемнәрен исәпләп бару өчен персональ лицевой счетлар ачыла. Хәзер гамәлдә булган тәртиптән аермалы буларак, эш бирүчеләр кертемнәрне һәм эшләүчеләрнең хезмәт хакыннан һәм чигерүләрнең дәүләт тарафыннан билгеләнгән үлчәмнәреннән чыгып исемләп күчереп барачак. Индивидуль хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затларга да шул ук тәртип кагыла.

Иминият кертемнәре түләп барылган хезмәт эшчәнлеге чоры иминият стажын тәшкил итә. Әйе, нәкъ менә иминият стажы, ә һич тә элеккегечә хезмәт стажы түгел, һәм пенсия күләме дә шәхси (лицевой) счетта тупланган иминият кертемнәреннән чыгып билгеләнәчәк.

Шунысы бик мөһим, персональ шәхси счетларның Россиянең бөтен территориясендә даими номеры булачак шул номер белән «иминият таныклыгы» биреләчәк.

Закон киләчәктә хезмәт кенәгәләрен юкка чыгаруны да күздә тота. Эшкә кергәндә дә, пенсиягә чыкканда да бердәнбер хокукый документ булып «иминият таныклыгы» торачак.

Страховать ителгән затлар турындагы барлык кирәкле мәгълүматларны аларга эш бирүчеләр яки Пенсия фондына иминият кертемнәрен үзләре мөстәкыйль түләүче затлар Пенсия фонды билгеләгән срокларда тапшыралар.

Яңа Закон буенча, страховать ителгән һәр зат үзенең иминият счетына кертемнәрнең тупланышын Пенсия фондыннан да, предприятиенең бухгалтериясеннән дә белешеп тора ала һәм аңа мәгълүмат бирмәскә бирәүнең дә хакы юк. Пенсия фонды исә пенсия билгеләүче органнарның соратуы буенча, страховать ителгән затларның шәхси счетларындагы мәгълүматларны бирергә бурычлы.

Барлык мәгълүматлар да компьютерга кертелгәнгә күрә, киләчәктә кешенең пенсиясен хисаплап чыгару санаулы минутлар эчендә үткәреләчәк.

Татарстан Республикасында персональләштерелгән исәп системасы этаплап, 1997 елның икенче яртысыннан башлап башта Казанда, аннан график буенча республиканың башка шәһәр һәм районнарында да кертеләчәк.

Хәзерге вакытта, хакимият башлыгы карары буенча, эш бирүчеләргә бу Законны үтәү чараларын күрә башларга кирәк. Шул максаттан предприятие һәм оешма җитәкчеләре 1 октябрьгә кадәр түбәндәгеләрне эшләргә тиешләр:

1. Персональләштерелгән учетны кертү эшләрен үзвакытында һәм сыйфатлы үткәрү өчен җитәкчеләр арасыннан җаваплы кеше билгеләү турында әмер чыгарырга;

2. Бухгалтерия, кадрлар, финанс службасының компьютерда эшләү тәҗрибәсе булган белгечләре составында персональләштерелгән учет эшләрен үткәрү буенча эшче төркем төзергә. Коллективларда персональләштерелгән учетның максатын һәм бурычларын аңлату эшләре алып барырга.

Башка илләр практикасы күрсәткәнчә, персональләштерелгән учет системасын кертеп бетергәнче берничә ел вакыт үтәчәк.

Пенсионерлар борчылмасыннар, чөнки аларның пенсия кәгазьләренә берни дә булмаячак, әмма аларның да һәммәсенә шәхси (лицевой) счет ачылачак.

Һәм соңгысы. Бу Законны гамәлгә кертү эше расланган инструкция нигезендә генә булачак.

**В.ХОМЕНКО,**

**Пенсия фондының Октябрь районы буенча баш уполномоченные.**

## Хәйләкәр көя

Кеше кимерүчеләргә һәм бөҗәкләргә каршы алар өчен әшәке яңа гына берәр чара уйлап таптымы - ул тиздән мәгънәсезгә әверелә: хәйләкәр күселәр, бөҗәкләр һәм көя аларга җайлаша. Җирдәге фауна вәкилләре һөнәргә бик һәвәс. Алар арасында слесарьлар да, балта осталары, буяучылар, тукучылар, тимерчеләр, укчылар да бар. Һәр оста ике мөһим бурычның берсен хәл итә - дошманнан ничек котылып калырга да азык ничек табарга. Хайваннар һәм бөҗәкләрнең хәйләкәрлеге галимнәр өчен шуңа дәлил булып тора: алар күп һөнәрне кешедән дә начаррак үзләштерми.

Үзәк Америка урманында яшәүче маймыллар, мәсәлән, йөз процент төгәллек белән «бомбага тоту»ны үзләштергәннәр. Үрмәле үсемлек ярдәмендә агачтан агачка сикергәндә, алар үзләренә ошамаган узып баручының башына бушаналар.

Швеция яр буенда оялаучы ала каргалар, боз астыннан балык тотучыларны күзәтеп, кешеләр үзләренең боздагы тишекләрдә калдырып киткән кармакларын карарга килгәнче, ягъни иртәнге якта суалчан һәм вак балык ауларга мөмкин булуын төшенгәннәр. Алар кармак җебен томшыклары белән кабалар да, җим яки җимгә эләккән балык боз өстенә чыгып җиткәнче, аны өскә өстериләр.

Африка урман кандаласы үзенең мәкерлеге белән күбәүләрдән өстен тора. Термитны тотып алып һәм аны суырып бетереп, ул буш кабыкны тәпиенә кия дә аны термит оясына керә торган урында болгый башлый. Үлгән иптәшен алырга тышка чыккан термит үзе дә шундук канэчкечнең корбанына әйләнә.

**«ШПИГЕЛЬ» журналыннан. Германия.**

● *Сәламәт булasыгыз килсә*

# БАЛЫК МАЕ ЭЧЕГЕЗ!

Кечкенә вакытта әти - әниләрнең безне көчләп диярлек балык мае эчерүләре күңелдә куркыныч истәлек булып калган. Әйе, аны рахит булмасын, күз күреме начарланмасын өчен эчерәләр иде. Чөнки балык маенда А һәм Д витаминнары бик күп. Ә галимнәрнең соңгы ачышлары буенча, бу майның дәрәҗәсе витаминнар булуда гына түгел икән. Балык мае составында безнең организмның һәрбер күзәнәге өчен мөһим булган омега - 3 дип аталучы махсус кислоталар бар. Бу кислотаны организм үзе эшләп чыгара алмый - ул ризык аша гына керә. Ә әзер килеш ул бары тик балык маенда гына бар. Илленче еллар уртасында Дания галимнәре Гренландия ярларында яшәүче эскимосларның ничек тукलануларын һәм сәламәтлекләрен тикшерәләр. Ни гаҗәп - май һәм аксымны коточкыч дәрәҗәдә күп ашауга карамастан, аларда йөрәк - кан авырулары дөрес итеп тукланучы даниялеләргә караганда бик күпкә ким булып чыга. Ләкин эскимослар Даниягә күчеп, европача туклана башлагач, йөрәк - кан авыруыннан җирле халык кебек интегә башлыйлар.

Әйе, балык маенең файдасы әйтеп бетергесез. Хәзер дөнья табиблары аны йөрәктәге ишемия авыруы, шикәр диабеты, төрле тын юллары, тире һәм күз авырулары, полиартритларны дәвалаганда кулланалар.

***P.S. Хәзер балык мае бернинди дә тәм килми торган итеп желатин капсулаларында (безнең илдә эшләнгәне дә, чит илнеке дә) чыгарыла. Тартмасына омега - 3 кислотасы барлыгын күрсәткән марка ябыштырылган булырга тиеш.***

# «Трассовиклар» юлда булса...

Без гадәттә шәһәр эчендә, зур трассаларның эре борылышларында гына күрергә күнеккән «ГАИ»чыларны хәзер кайда гына очратмыйсың: төп трассаларның без күз алдыбызга да китерә алмаган участокларыннан киләләр дә чыгалар. Тизлекне арттырдыңмы, юл йөрүнең башка кагыйдәләрен боздыңмы - һичнинди аклану, башка төрле сәбәпләрне игътибарга алмыйча, гадел җәза бирәчәкләр үзеңә. Шуңа да хәзер шоферларның байтагы торак пунктларда гына түгел, трассаларда да сак булырга, алларын - артларын карап йөрергә тырышалар.

Халык телендә «Трассовиклар» дип йөртәләр аларны. Рәсми телдә исә юл - патруль службасы полкы (ПДПС) хезмәткәрләре дип атыйлар. Турыдан - туры Татарстан Республикасы эчке эшләр Министрлыгының ГАИ идарәсенә буйсынып, Әлмәт шәһәрендәге шундый полк белән бер взвод тәшкил итәләр. Норлат - Әлмәт юлының 87, Аксубай юлының 59 километрына Норлат «трассовиклары» хуҗа. Юлларда аварияләрне, тәртип бозуларны кисәтү, рэкетчылар, башка төрле җинаятьләр белән көрәшү - полк хезмәткәрләренең төп вазифалары шулар. 1993 нче елда аерым батальон буларак оешып, тора - бара полкка әйләнгән юл - патруль службасы үзен тиз арада уңай яктан күрсәтә алды. Быелның сигез аенда трассада юл - транспорт һәлакәтләренең саны узган елның шул чорындагыдан артмавы, юлда җәрәхәт алучыларның саны сизелерлек кимүе дә шул хакта сөйли. Шушы чорда былтыргы белән чагыштырганда бер җинаятьнең күбрәк һәм барлыгы 13е ачылуы да шул хакта сөйли. Ялган документ белән йөрүчеләр, караклар, үзләре белән салкын корал йөртүче күпме кеше фаш ителеп, тиешле җәзасын алды.

Билгеле инде, трассаларда тәртип сагында торган кешегә игътибарлы да, күзәтүчән дә булырга кирәк. Ә биредә эшләүчеләрнең байтагы шушы сыйфатларга ия. Өлкән инспектор милиция өлкән лейтенанты Рәфис Хәсәнов, инспектор, старшина Илшат Хәйруллин бу сыйфатларның барысына да ия егетләр. Һава шартларының нинди булуына карамастан, вакыт белән исәпләшмичә (служба ике сменада эшли) постта торалар алар. ПДПСның взвод командиры урынбасары (командиры Әлмәттә) Рәис Нугаев та коллективның ихтирамын казанган җитәкче. Район эчке эшләр бүлегенең дәүләт автоинспекциясенә эшкә 1986 нчы елда Чистай совхоз -техникумын тәмамлаганнан соң килгән иде ул.

Тырыш егет тиз арада үз эшенең бөтен нечкәлекләренә төшенде, коллективта абруй казанды. Рәис Усмановичның ДПС полкына җитәкчелек итә башлавына да дүртенче ел китте инде. Ул үз кулы астында эшләүче 14 юл күзәтүчесенең дә эшен дөрес оештыру, полк карамагындагы трассаны даими игътибар үзәгендә тоту, боларның һәрберсенең төп максат - юлларда хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерү өчен тырыша.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# ЭКЗОТИК ҖИЛӘК - ҖИМЕШЛӘР

***Аларның кеше организмына файдасы бармы?***

***АНАНАС***. Өлгергән ананаста азыкны эшкәртергә ярдәм итә торган аксымны таркатучы бромелин ферменты бар.

***АВОКАДО***. Аның җимешләре туендырылмаган май кислоталарына һәм Е витаминына бай.

***БАНАН***. Составында углеводлар күп булу белән бик туклыклы. Анда күптөрле витаминнар һәм минераль тозлар бар. Аны күбрәк ашасаң, эчне ныгыта. Шуңа күрә аны эч йомшарганда тәкъдим итәләр.


***КИВИ.*** Ул С витаминына бай. Бер җимеше С витаминына булган тәүлеклек ихтыяҗны каплый.

***МАНГО.*** Аның җимеше А провитаминына (каротинга) гаять бай.

***ПАПАЙЯ.*** Бу кавын агачы җимешләрендә А һәм С витаминнары күп.

***ИНҖИР.*** Сәламәтлек һәм матурлык өстәүче продуктлар исәбенә керә. Ул эчәкләрне бик яхшы чистарта һәм канны яхшырта. Өлгергән инҗир (шулай ук кипкәне дә) тамакка, югары сулыш юлларына һәм үпкәгә салкын тигәндә, шулай ук үпкәдәге шешләрне дәвалаганда бик файдалы.

***ХӨРМӘ.*** Акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өчен файдалы. Ул баш миен тукландыру өчен кирәк булган микроэлементларга: фосфор, кобальт, бакыр һ.б. бай. Хөрмә шулай ук баш миендәге кан юлларын да чистарта.




# ТРАГЕДИЯЛЕ ТУГАНЛЫК

**Филадельфиянең бер обывателе, түбәндәге язуны язып калдырып, үз - үзен үтергән:**

*«Мин бер тол хатынга өйләндем. Ул хатынның җиткән кызы бар иде. Минем әти шул үги кызыма гашыйк булды. Һәм аңа өйләнеп тә куйды. Шулай итеп, әти минем киявем булды, ә үземнең үги кызым, әтиемнең хатыны булгач, минем әни булып китте.*

*Минем хатын бер ир бала тапты, ул инде минем әтигә кайнеш була һәм, үги анамның энесе буларак, үз улым миңа абый туры килә.*

*Әтиемнең хатыны да ир бала тапты. Ул инде, билгеле, минем энекәшем була, шулай ук кызымның улы буларак, минем баламның баласы була.*

*Шул рәвешчә, минем хатын, әниемнең әнисе буларак, минем әби булды - ә мин бер үк вакытта хатынымның ире дә, баласының баласы да булып киттем. Шулай итеп, кемнең дә булса әбисенең ире шул ук кешегә бабай туры килгәч, мин дә инде үземә - үзем бабай булдым!»*

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Биккол авылында яшәүче тормыш иптәшем, әтиебез **Шакирҗан Сөләймановны** 18 сентябрь көнне 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз. Сиңа исәнлекле тормыш, озын гомер телибез.

**Тормыш иптәшең, улларың, киленнәрең, оныкларың.**

## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21013, бәясе килешү буенча**. Тел.:2-29-54

* * *

**1996 елгы зөбәрҗәт төсендәге ВАЗ - 21099, 32 мең км. юл үткән, сигнализациясе бар**. Тел.:2-11-85.

* * *

**Ашыгыч рәвештә 4 бүлмәле фатир сатыла яки өстәмә түләү шарты белән 2 бүлмәлегә алыштырыла.** Циолковский ур., 20 адресына мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**1993 елгы «ЛУАЗ - 969»**.Тел.: 5-19-45.

* * *

**Тимер юл поселогында бакча участогы.** Адрес: Циолковский ур., 9 - 34.

* * *

**1991елгы «ВАЗ - 2105», 1993 елгы «Урал» мотоциклы, 1000 км. юл үткән. Бәясе - килешү буенча.** Адрес: Погрузная станциясе, Завод ур., 25 - 9.

* * *

**1986 елгы әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2108.** Тел.: 2-22-59.

* * *

**Рус Тимерлегендә усадьба, бәясе - килешү буенча.** Евдокимова З.М.га мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**3,5 х 5 метрлы мунча бурасы.** Тел.: 2-21-95.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Красноармейская урамында йорт сатыла яки бер бүлмәле фатирга алмаштырыла.** Адрес: Дружба ур., 78 - 64. Тел.: 5-12-32.

* * *

**1 нче урта мәктәпкә шофер - инструктор һәм столяр - балта остасы кирәк.**

* * *

**5 яшьлек кызыл - чуар сыер югалды, колак очы кискән, маңгаенда ак табы бар.** Күрүчеләрне бүләк бәрабәренә Кормыш поселогында Хәйбуллинага мөрәҗәгать итүен сорыйбыз.

* * *

**Линейная урамында 19 - 1 номерлы 3 бүлмәле фатир 2 һәм 1 бүлмәлегә алмаштырыла, мунчасы, бакчасы бар. Вариантлар ихтимал**. Куйбышев ур., 26 - 3 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**«Татнефть» акцияләре сатып алабыз.**
Адрес: К.Маркс ур., 12. Тел.: 2-19-30.

* * *

**2 бүлмәле фатир өстәмә түләү шарты белән 1 бүлмәлегә алыштырыла яки сатыла.**
Адрес: Завод ур., 25 - 8.


## *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 26 сентябрь, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


***Н.Октябрь район элемтә узелы бурычлары булган шәхси сектор хуҗаларын, предприятие, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләрен 20 сентябрьгә кадәр исәп - хисап ясарга чакыра.***

***Бурыч түләнмәгән очракта элемтә министрының 21.09.97 елгы 111/1010 номерлы телеграммасы нигезендә телефоннарны өзеп, түләү сәләте булган клиентларга тапшыру буенча чаралар күреләчәк.***

«Норлатнефть» НГДУсы коллективы әниләре Мәллафа Нургали кызының үлүе сәбәпле «Норлатнефть» НГДУсы эшчеләрне тәэмин итү бүлеге начальнигы Вәсилә Нурлыгаяновна Хуҗинаның, «Норлатнефть» НГДУсы начальнигы Марат Мөхлисович Хуҗинның, НГДУның спорт - сәламәтләндерү цехы шәфкать туташы Кадыйрова Зәбирә Нурлыгаяновнаның тирән хәсрәтләрен уртаклаша.

«Норлатнефть» НГДУсы коллективы әбисе һәм хатынының әнисе Мәллафа Нургалиевнаның үлүе сәбәпле НГДУның кадрлар бүлеге инженеры Ильясова Лилия Маратовна һәм газ участогы мастеры Кадыйров Рифат Акмаевичның авыр кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә. Заказ № 8795.